РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 15 декабре Кукмара ш. № 164

Аренда түләвен кичектерү, штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда килешүләрен өзү мөмкинлеге турында

Кукмара муниципаль районы Советы гражданнарга (шул исәптән шәхси эшмәкәрләргә) һәм оешмаларга өлешчә мобилизацияләнүгә бәйле рәвештә ярдәм итү максатыннан **карар бирде:**

1. Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил иткән, алар буенча арендаторлар булып физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар торган мөлкәтнең (шул исәптән җир кишәрлекләрен) аренда шартнамәләре буенча, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булып шул бер үк физик зат торса, әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр яисә юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм җитәкчесе булып торган физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган булса, яисә «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты (алга таба – Федераль закон) нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт уза торган булса, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән булса, түбәндәгеләрнең берелүен тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектерү (алга таба – аренда түләвен кичектерү);

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлекләре.

2. Әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән зат тарафыннан аренда түләвен кичектереп тору чорында шартнамә буенча арендалана торган мөлкәттән файдаланмау;

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен кушып, аренда түләвен кичектерү бирү турында хәбәрнамә яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзү хакында хәбәрнамә яисә күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт күчермәләрен җибәрә;

әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән арендаторга әлеге карарның 4 пункты нигезендә исәпләнә торган чорга аренда түләвен кичектерү бирелә;

аренда түләве буенча бурыч аренда түләвен кичектереп тору чоры тәмамланганнан көннән башлап аренда шартнамәсенә өстәмә килешү нигезендә этаплап, күп дигәндә айга бер тапкыр, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмый торган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

аренда түләвен кичектерүгә бәйле рәвештә арендатор түләргә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорда арендаторның аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда да) үтәмәвенә бәйле рәвештә штрафлар, башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый.

3. Штраф санкцияләрен кулланмыйча, әлеге карарның 1 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән аренда шартнамәсен өзү түбәндәге шартларда гамәлгә ашырыла:

арендатор, шул исәптән ышанычлы затлар аша, арендага бирүчегә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәт узу статусын раслый торган документларның күчермәләрен кушып, аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзү хакында хәбәрнамә яисә күрсәтелгән контрактлар төзелгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бирелгән Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт күчермәләрен җибәрә;

аренда шартнамәсе арендага бирүче тарафыннан аренда шартнамәсен өзү турында хәбәрнамә алган көннән өзелергә тиеш;

аренда шартнамәсе өзелүгә бәйле рәвештә штрафлар, башкаларның акчаларыннан файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары кулланылмый (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда да).

4. Аренда түләвен кичектерү срогы 90 көнгә арттырылган мобилизация срогы буларак исәпләнә, һәм һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның хастаханәләрдә, госпитальләрдә, башка медицина оешмаларында мобилизация чорында бурычларны үтәгәндә алынган гариплектән (җәрәхәтләнүдән, җәрәхәттән,

контузиядән) яки авырудан дәваланууда булу чорына, ә әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затны хәбәрсез югалган дип тану очрагында – шулай ук аны билгесез югалган дип тану турында суд карарын гамәлдән чыгарганчы яисә суд тарафыннан аны үлгән дип игълан ителгәнчегә кадәр озайтыла.

Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән затның һәлак булуы (үлеме) очрагында, әгәр дә ул мобилизация чорында яки күрсәтелгән чордан соң, ләкин мобилизация чорында алынган гарипләнү (яралану, җәрәхәтләр, контузия) яки авыру аркасында һәлак булса (үлсә), шулай ук аны Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип таныган очракта, кичектерелгән вакыт өчен аренда түләве түләтелми.

Үлемгә яисә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә I төркем инвалиды дип танылуга китергән гарипләнүнең (яралануның, җәрәхәтләрнең, контузияләрнең) яки авыруның мобилизация чоры белән сәбәп бәйләнеше хәрби-табиб комиссияләре һәм (яки) Федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан билгеләнә.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль предприятиеләренә һәм муниципаль учреждениеләренә, хуҗалык алып бару хокукында яисә муниципаль предприятиеләргә оператив идарә итү хокукында яисә муниципаль учреждениеләргә оператив идарә итү хокукында беркетелгән, алар буенча арендаторлар булып физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар торган муниципаль мөлкәтнең (шул исәптән җир кишәрлекләрен) аренда шартнамәләре буенча, аларда юридик затның бердәнбер гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм аның җитәкчесе булып шул бер үк физик зат торса, әгәр әлеге физик затлар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр яисә юридик затның гамәлгә куючысы (катнашучысы) һәм җитәкчесе булып торган физик затлар Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган булса, яисә Федераль законның 38 статьясындагы 7 пункты нигезендә төзелгән контракт буенча хәрби хезмәт уза торган булса, йә Россия Федерациясе Кораллы көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм итү турында контракт төзегән булса, түбәндәгеләрнең берсен тәэмин итәргә:

а) әлеге карарның 4 пунктында күрсәтелгән чорга аренда түләвен кичектерү;

б) штраф санкцияләрен кулланмыйча, аренда шартнамәләрен өзү мөмкинлекләре.

6. Әлеге карарның 5 пунктының «а» пунктчасында күрсәтелгән аренда түләвен түләүне кичектерү бирү әлеге карарның 2 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

7. Штраф санкцияләрен кулланмыйча, әлеге карарның 5 пунктындагы «б» пунктчасында күрсәтелгән аренда шартнамәсен өзү әлеге карарның 3 пунктында каралган шартларда гамәлгә ашырыла.

8. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына муниципаль милектә булган мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектерү мөмкинлеген һәм әлеге карарның 1 - 7 пунктларында каралган нигезләмәләрне исәпкә алып,

штраф санкцияләрен кулланмыйча аренда шартнамәләрен өзүне тәэмин итә торган чаралар күрергә тәкъдим итәргә

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 21 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

10. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев